РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» 06 2019 г. №420

Алкоголь продукциясен данәләп

сатуны чикләү турында

1995 елның 22 ноябреннән булган «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аның әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында»гы 171санлы Федераль закон һәм 2011 елның 18 июленнән булган «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аның әйләнешен дәүләти җайга салу турында Федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы № 218 Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге "Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар территорияләре чикләрен билгеләү турында”гы № 1425 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 29 октябрендәге “Татарстан Республикасы халкы арасында алкоголь продукциясен, сыраны, тәмәке куллануны киметү һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында”гы 867 санлы карары һәм 2011 елның 24 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында"гы №788 карарына ярашлы, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә «Сабан туе -2019» халык бәйрәме уздырган көннәрдә стационар булмаган сәүдә объектларында, шулай ук

гражданнарның күпләп җыелу урыннарында алкогольле һәм аз градуслы продукция сатуны гамәлгә ашыруга юл куймаска киңәш итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

Г.Г. Габдрахманова

2-74-97